Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

№ 7 13 ноябрь 2023 ел

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 26 ноябрендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай торак пунктында үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан,контракт буенча хәрби бурычын үтәүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- тирәнлек насосын ремонтлау һәм алыштыру, суүткәргечне ремонтлау (товарлар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

2. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Кече Аксубай торак пункты территориясендә үсентеләрне сукалау (ягулык-майлау материаллары, чыгым материаллары сатып алу )

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Аксубай районы Кече Аксубай авылының Лесная урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан йорт янында гражданнар җыенын уздырырга.

4. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А.В.Макаров